КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 8 декабрь г.Казань № 1588

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген раслау турында» 2021 ел, 24 декабрь, 1279 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген раслау турында» 2021 ел, 24 декабрь, 1279 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 9 февраль, 104 нче һәм 2023 ел, 3 февраль, 89 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге юлдан соң:

| | | |
|---|---|---|
| «395 | | Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды» |

түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «395 | 1 02 13000 08 1000 160 | Эшләмәүче халыкны мәҗбүри медицина иминләштерүе өчен иминият кертемнәре (түләү суммасы (тиешле түләү буенча яңадан исәпләүләр, недоимка һәм бурыч, шул исәптән гамәлдән чыгарылган түләү буенча)); |

түбәндәге юлны:

| | | |
|---|---|---|
| «395 | 2 02 55257 09 0000 150 | Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондының нормалаштырылган иминият запасын формалаштыруны финанс белән тәэмин итү өчен мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «395 | 2 02 55257 09 0000 150 | Табиблар һәм урта медицина персоналы хезмәте өчен түләүгә медицина оешмалары чыгымнарын финанслашу максатларында территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар»; |

түбәндәге юлны:

| | | |
|---|---|---|
| «395 | 2 02 58501 09 0000 150 | 2021 – 2022 елларда Россия Федерациясе субъектлары һәм Байконур шәһәре территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына мәҗбүри медицина иминияте буенча иминләштерелгән затларга, шул исәптән яңа короновирус йогышлы авыруы белән авыручы һәм (яисә) авыруга карата шик белән, территориаль мәҗбүри медицина иминияте программаларын гамәлгә ашыру кысаларында медицина ярдәме күрсәтүне өстәмә финанс белән тәэмин итүгә тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» |

төшереп калдырырга;

түбәндәге юлдан соң:

| | | |
|---|---|---|
| «395 | 2 02 90073 09 0000 150 | Мәҗбүри медицина иминияте федераль фонды бюджетыннан мәҗбүри медицина иминияте фонды территориаль бюджетларына кире кайтарылмый торган башка керемнәр» |

түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «395 | 2 03 09099 09 0000 150 | Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондлары бюджетларына дәүләт (муниципаль) оешмаларыннан кире кайтарылмый торган башка керемнәр |

юллар

| | | |
|---|---|---|
| «395 | 2 07 10090 09 0000 191 | Юридик затның кире кайтарылмый торган акча булмаган кертемнәре (мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондлары бюджетлары) |
| 395 | 2 07 10090 09 0000 193 | мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондлары бюджетларына бюджет (автоном) учреждениеләреннән кире кайтарылмый торган ведомство акча булмаган кертемнәр» |

төшереп калдырырга;

түбәндәге юлны:

| | | |
|---|---|---|
| «395 | 2 19 55622 09 0000 150 | Россия Федерациясе субъектларының һәм Байконур шәһәренең чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү максатларында бюджетара трансфертларның калган өлешләрен территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларыннан яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) кичергән, мәҗбүри медицина иминияте территориаль программасын гамәлгә ашыру кысаларында мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондлары бюджетларыннан Россия |

| | | |
|---|---|---|
| | | Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды акчалары исәбеннән яңадан диспансеризация үткәрүне финанс белән тәэмин итүгә кайтару» |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «395 | 2 19 55622 09 0000 150 | Мәҗбүри медицина иминияте территориаль программасын гамәлгә ашыру кысаларында яңа коронавирус инфекциясе (COVID-19) белән авырган, мәҗбүри медицина иминияте буенча иминләштерелгән затларга тирәнтен диспансеризация үткәрүне финанс белән тәэмин итүгә бюджетара трансфертларның калган өлешләрен мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондлары бюджетларыннан кире кайтару»; |

түбәндәге юлдан соң:

| | | |
|---|---|---|
| «395 | 2 19 55849 09 0000 150 | Россия Федерациясе субъектларының һәм Байконур шәһәренең чыгым йөкләмәләрен өстәмә финанс белән тәэмин итү максатларында бюджетара трансфертларның калган өлешләрен территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларыннан мәҗбүри медицина иминияте буенча иминләш-терелгән, шул исәптән (COVID-19) йогышлы авыруы кичергән һәм (яисә) авыруга шикләнү белән, мәҗбүри медицина иминияте территориаль программасын гамәлгә ашыру кысаларында мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондлары бюджетларыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды акчалары исәбеннән яңадан медицина ярдәме күрсәтүне финанс белән тәэмин итүгә кайтару» |

түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «395 | 2 19 55854 09 0000 150 | Россия Федерациясе территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларыннан территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын гамәлгә ашыру кысаларында яңа короновирус йогышлы авыруы (COVID-19) белән авыручы һәм (яисә) авыруга карата шик белән иминләштерелгән затларга беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүне өстәмә финанс белән тәэмин итүгә калган бюджетара трансфертларны кире кайтару». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин